# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлегенең Воробьевка авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 18 ноябре №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Ослан җирлеге Уставының 24 статьясы, 22.11.2013 № 909 ел (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Воробьевка авылы торк пунктында халык җыены
КАРАР ИТТЕ:
Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авылы җирлегенең Воробьевка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 100% -СВОда катнашучылар, контрактчылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 төркем инвалидлар; 50% - күп балалы гаиләләр, көндезге уку йортлары студентлары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 2026 елда үзара салымны 42 943 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
Воробьевка авылында су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аларны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка җиткерүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (урамнарны су белән тәэмин итү системасына экспертиза ясап).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев